ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.09.2025 г. Заинск № 435

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеген раслау турында**

«Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.4 маддәсенең 3 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иреклелек (волонтерлык) үсеше өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы турында» 2019 елның 17 августындагы 1067 номерлы карары нигезендә, «Иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 3 пунктын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга күрсәтелә торган ярдәм чаралары исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Игелек. "Игелекле Зәй" үзәгенә «ДОБРО.РФ» иреклелек (волонтерлык) үсеше өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла торган ярдәм чаралары турында мәгълүматны вакытында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р. И. Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.Н. Камалова**

Шәрәфиева Г.М.
8(85558)9-90-91